МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.08.2021 г.Казань № 591

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 10 сентяберендә 7897 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 17 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 гыйнварындагы 46 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №401, 08.06.2017 №349, 18.05.2018 №383, 24.09.2018 №897, 04.02.2019 №77, 07.08.2019 №598, 14.11.2019 №1008, 08.05.2020 №289, 14.07.2020 №515, 08.10.2020 №709? 30.03.2021 №171 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлекчәсенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты, «Интернет» челтәре), «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) урнаштырылган. Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында;
Бердәм порталда.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Айлык акчалата түләү билгеләү.

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм шәһәр округындагы бүлекчәсе.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

телефонга смс-хәбәр итеп.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Айлык акчалата түләү билгеләү гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгәннән соң ун эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк булмаган чорга гына.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар имзаланган көннән алып бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, айлык акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

2.4.4. Айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган,

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) Банкта яисә башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза:

- әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча;

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2) Затның әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслаучы документларның күчермәләре.

3) 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарында каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән хезмәт ветераннары, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турындагы белешмәне тапшыра.

4) Хезмәт ветераннары өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – 542 номерлы Нигезләмә) кушымтасының 1 пунктындагы өченче абзацта һәм 2 пунктының бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны да тапшыралар.

2.5.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.3. Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.5.4. Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен

күрсәтеп тапшырыла, Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.5. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.5.6. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.7. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Үзәк бүлекчәсендә кәгазьдә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

3) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

2.5.8. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.9. Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

2.5.10. Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

төрләренең исемлеге 542 номерлы Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән затларга айлык түләү билгеләнгән очракта).

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең паспортының чынлыгын раслау турында мәгълүмат алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.2. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

2) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

3) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

4) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.

2) Мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларның 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 4-7 статьяларында билгеләнгән нигезләрдә яки федераль законнар нигезендә социаль ярдәм чараларын алуы, «Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә айлык акчалата түләү билгеләнү очракларыннан тыш;

гражданинның тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыруы;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса;

хезмәт ветеранының уртача айлык кереме 20 000 сумнан артып китүе;

хезмәт ветеранының төрләренең исемлеге 542 номерлы Нигезләмәдә күрсәтелгән керемнәрнең булмавы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре

булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны озата йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, хезмәт күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктала хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

Үзәк бүлекчәсенең мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында алынырга мөмкин.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә, үзара хезмәттәшлек итү таләп ителми;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Бердәм порталдан порталыннан алынырга мөмкин

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ

номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә

кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.4. Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

2.16.5. Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 нче бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче айлык акчалата түләү билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин.

Гариза һәм документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.»;

3.3.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта, шул исәптән электрон почта аша алганда Үзәк бүлекчәсе белгече, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен язмача аңлатып, документларны почта аша кайтара.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырылган очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә, – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә;

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итү турында язу, гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.»;

3.5.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3 нче, 6 нчы кушымталар нигезендәге формалар буенча электрон рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имза кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы 20 эш көненә арттырыла. Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын озайту хакында айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Процедураларның нәтиҗәсе: айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проекты, айлык акчалата түләү билгеләү турында яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын арттыру турында белдерү.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (язмача формада шәхсән яисә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, телефонга смс-хәбәр җибәрү юлы белән) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, айлык акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).»;

3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 3.9 пунктын өстәргә:

«3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата түләү билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 1 нче
кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ
№____ бүлекчәсе
____________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Гариза №____
__________ 20__ ел.

Мин,________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес:
_____________________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе:

______________________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауны раслый торган документ реквизитлары)

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә айлык акчалата түләү билгеләвегез турында үтенәм

______________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

СНИЛС (алучыныкы) _________________

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:

әлеге счетка күчерү юлы белән ______________________________________

(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта элемтәсе оешмалары аша ____________________________________

(мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең почта бүлекчәсе)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым __________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында мәгълүмат алуга риза:

почта адресы буенча язма формада _________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _______________________________________

(телефон номеры)

әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында___________________

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

_______________________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең имзасы

Мөрәҗәгать итүче:______________________________ __________ «__»______ 20__ ел.
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, (имза)
исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Яңа вакытка социаль ярдәм чараларын автомат рәвештә билгеләү белән килешәм________________________

Мөрәҗәгать итүче:____________________________ __________ «__»______ 20__ ел.
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, (имза)
атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_______________________________________________________________________________.
Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ____________ __________ ______________ _______________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата түләү билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) республика үзәге»
ДКУ №_____ бүлекчәсе

____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләү турында карар

№_________ «___» ____________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) ______________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Билгеләргә (бирергә):

| № | Социаль ярдәм чаралары | Түләү күләме | Билгеләнү датасы | Түләү вакыты ___башлап____ кадәр |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | _____ __ «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә айлык акчалата түләү[1] | | | ___башлап____ кадәр |

Түләү ысулы ________________________________________________________________

«Матди ярдәм (компенсация
түләүләре) республика үзәге»
ДКУ №____ бүлекчәсе мөдире

____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)___________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация
түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе
белгече

_____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) __________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга)[2]:
язмача __________________________________________
почта адресы буенча
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ________________________________
телефон номеры
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ________________________________________
Электрон почта адресы
бүлекчә белгече ______________________________ ______________
(Фамилия, исем, ата исеме) имза
«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша
_____________________________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең имзасы

------------------------------

[1] «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының тиешле статьясы яки тиешле статьясы һәм пункты күрсәтелә.

[2] Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын электрон формада рәсмиләштергәндә әлеге позиция тулыланмый.

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ
№____ бүлекчәсе

___________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар

№______ «__» ____________

___________________________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________________

_____ __ [3]«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тартырга.
Баш тарту сәбәбе: _____________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе

__________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ___________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

__________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ___________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
язмача ____________________________________
почта адресы буенча
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________
телефон номеры
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ___________________________________
Электрон почта адресы
«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы»

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

______________________________________________________________________________

мөрәҗәгать итүченең имзасы

бүлекчә белгече ___________________________ ________________________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

--------------------------------

[3] «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының тиешле статьясы яки тиешле статьясы һәм пункты күрсәтелә.»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата түләү билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ
№____ бүлекчәсе

_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,_____________________________________________________________________,

(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

яши торган адрес:

______________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

______________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ исеме, аның сериясе,

______________________________________________________________________________.

номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы)

техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________,

______________________________________________________________________________,

җибәрелгән (кирәклесе астына сызарга):

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында

_______________ №______________ карарда.

(карар датасы) (Карар №)

айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында

___________ №_________ карарда.

(карар датасы) (Карар №)

Үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турындагы хәбәрне түбәндәгечә алуга риза:
язмача ________________________________________
почта адресы буенча
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________
телефон номеры
әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында__________________
«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша
___________________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең имзасы
Мөрәҗәгать итүче:___________________________ _________ «__»______ 20__ ел.
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имза)

Регламентка 6 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ
№___ бүлекчәсе
________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар

№_______ «__» ____________

___________________________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Мөрәҗәгать итүченең адресы _____________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы сәбәпле, айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне бурычларны түләгәнчегә кадәр, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә озаграк булмаган чорга туктатып торырга.

Бүлек җитәкчесе ____________________ ____________________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны

Бүлекчә белгече _______________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):

язмача ________________________________________

почта адресы буенча

смс-хәбәр белән _______________________

телефон номеры

_____________________________ электрон почтасы аша

электрон почта адресы

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

____________________________________________________________________________

мөрәҗәгать итүченең имзасы

Бүлекчә белгече ________________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ
№____ бүлекчәсе

_________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәру турында карар

№__________ «___»_____________

____________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салу белән бәйле рәвештә, айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте «__» ________ күрсәтүне яңартып җибәрергә.

Бүлек җитәкчесе _____________________ ______________________________

(Фамилия, исем, ата исеме) имза

Мөһер урыны

Бүлекчә белгече ________________________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):

язмача ________________________________________

почта адресы буенча

смс-хәбәр белән ______________________
телефон номеры

____________________________ электрон почтасы аша
Электрон почта адресы

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

________________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең имзасы

Бүлекчә белгече ______________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме) имза».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №395, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, 15.05.2018 №367, 24.09.2018 №897, 21.02.2019 №129, 19.04.2019 №285, 10.09.2019 №688, 14.11.2019 №1007, 05.02.2020 №65, 08.05.2020 №289, 14.07.2020 №515, 28.10.2020 №764, 30.03.2021 №171, 21.05.2021 №331 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) боерыгы белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлекчәсенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru)

(алга таба – Министрлыкның рәсми сайты, «Интернет» челтәре), «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) урнаштырылган. Теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалану өчен бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарын каплау өчен субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм контрольлек башкаручы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турындагы белешмәләр әлеге Регламентның белешмә кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында;

Бердәм порталда.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия

Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлга айлык акчалата түләү билгеләү.

### 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм шәһәр округындагы бүлекчәсе.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

телефонга смс-хәбәр итеп.

### 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгәннән соң ун эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.

2.4.3. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар имзаланган көннән алып бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, юлга айлык акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

2.4.4. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) Социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, юлда йөрү өчен айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза:

- әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән, мөрәҗәгать итүченең милеге булып торган күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре.

3) Мөрәҗәгать итүчедә законнар нигезендә мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның катлаулы формасы булуы турында белешмә.

4) 2018 елның 31 декабренә «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүләре турында белешмә тапшыралар.

5) Бала тууны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе.

6) Юлга айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырыла торган очракта, ышаныч кәгазенең күчермәсе.

7) 23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүче урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча укыган очракта, аның стипендия алмау факты турында документ күчермәсе;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – 542 номерлы Нигезләмә) кушымтасының 1 пунктындагы өченче абзацта һәм 2 пунктының бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документлар.

2.5.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.3. Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.5.4. Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

2.5.5. Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.6. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.5.7. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза кәгазенең электрон формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.8. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

2.5.9. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.10. Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә гаризаны Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

күчемсез мөлкәт булуы турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

төрләренең исемлеге Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән керемнәр турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында;

опека (попечительлек) билгеләнүе турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр полртады аша яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәт инфоматлары аша мөрәҗәгать иткәндә өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:

мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турында белешмәләр;

яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүчене теркәүнең чын булуын раслау турында белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.2. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.

2) Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча булмаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы;

гражданинның тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыруы;

мөрәҗәгать итүчеләрдә төрләренең исемлеге әлеге Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән керемнәрнең булмавы, 23 яшьтән кечерәк, гомуми белем бирү оешмаларында, урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларында көндезге формада белем алучы мөрәҗәгать итүчеләрдән тыш;

мөрәҗәгать итүченең уртача айлык кереме 20 000 сумнан артып киткән очракта;

мөрәҗәгать итүченең мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» - «г», «е», «ж» пунктларында билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән артып китүе.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Гариза һәм документлар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

2.12.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында

каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.15.2. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

Үзәк бүлекчәләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеlә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматларында, Бердәм порталда алынырга мөмкин.

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга.

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул

ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.4. Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

2.16.5. Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 нче бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.5.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнаша торган затның яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештә карар проекты рәсмиләштерә;

юлга айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын имзалау өчен электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынганнан соң ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, юлга айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы 20 эш көненә арттырыла. Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә юлга айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын озайту хакында юлга айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Процедураларның нәтиҗәсе: юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештә карар проекты, юлга айлык акчалата түләү билгеләү турында яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын арттыру турында белдерү.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (язмача формада шәхсән яисә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, телефонга смс-хәбәр җибәрү юлы белән) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, юлга айлык акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).»;

3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 3.9 пунктын өстәргә:

«3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;